ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
05.02.2024

**К А Р А Р**
№ 100

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча 2024 елга халык өчен торак хезмәтләре тарифларын раслау турында» 2023 елның 29 декабрендәге 1983 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта хезмәт күрсәткәндә һәм гомуми мөлкәтне идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр тиешле сыйфатсыз һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артыграк өзеклекләр белән башкарылган очракта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципального района Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча 2024 елга халык өчен торак хезмәтләре тарифларын раслау турында» 2023 елның 29 декабрендәге 1983 номерлы карары белән расланган 2 нче кушымтаны яңа редакциядә Кушымтага ярашлы бәян итәргә.
2. Әлеге карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча бастырып чыгарырга.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

ТР Биектау муниципаль
районы башкарма
комитетының
2024 елның 5 феврале
100 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча наемлаучыларга торак бинадан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү Тәртип турындагы нигезләмәгә яршлы наем өчен түләү күләмен исәпләү**

Наем өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Пн = Нбаз \times \frac{К1 + К2 + К3}{3} \times Ксп \times S,$$

монда:
Пн – торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме;
Нбаз – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында 1 кв.м торак урынны наемга алган өчен түләүнең база күләме – 125,36 сум;
Ксп – түләүнең туры килү коэффициенты:
социаль наем шартнамәләре буенча – 0,071;
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча –0,071;
S – социаль наем шартнамәсе яисә дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урынын наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынның гомуми мәйданы (кв.м).

К1 түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К1 = \frac{Км + Ксв + Кпл}{3},$$

монда:
К1, К2, К3, Км, Ксв, Кпл – таблицада күрсәтелгән коэффициентлар.

Таблица

| Коэффициент | Кулланучылар үзлекләре | Коэффициент кыйммәте |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Торак урынның сыйфатын характерлаучы коэффициентлар (К1) | | |
| $К_м$ | Стеналар материалы:<br>- кирпеч, таш;<br>- блоклы, эре панельле;<br>- катнаш яки агач | <br>1,3;<br>1,1;<br>0,8 |
| Ксв | Иортны кертү сроклары:<br>- 2011 елдан;<br>- 1991 дән 2010 елгача;<br>- 1971 дән 1990 елгача;<br>- 1951 дән 1970 елгача;<br>- 1950 елга кадәр | <br>1,3;<br>1,2;<br>1,0;<br>0,9;<br>0,8 |
| Кпл | Торак урынны планлаштыру:<br>-яхшыртылган;<br>- стандарт;<br>- стандарт булмаган (шул исәптән, коммуналь, кунакханә һәм барак тибындагы, тулай торак) | <br>1,3;<br>1,1;<br>0,8 |
| Коэффициент, характеризующий благоустройство жилого помещения (К2) | | |
| - | Торак урынынын төзекләндерү:<br>- төзекләндерүнең барлык төрләре: салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү, үзәкләштерелгән су чыгару, җылылык (мичтән тыш), электр белән тәэмин итү;<br>- төзекләндерүнең бер төре булмау;<br>- төзекләндерүнең бердән артык төре булмау | <br>1,3;<br><br><br>1,0;<br>0,8 |
| | Иортның урынын тасвирлаучы коэффициент (К3) | |
| | Урнашкан урыны:<br>Биектау муниципаль районы торак пункты: | 1,3 |